


На конкурс «Школьный урок по теме «История политических репрессий и сопротивления несвободе в СССР».

“Балык Бистәсе 2нче
номерлы гомуми урта белем
бирү мәктәбе” МГББУ укытучысы
Токранова Эльвира Ильяс кызы

Конспект внеклассного мероприятия
по татарской литературе для 8-11 классов

**Прости (Кичер)**

(литературная композиция, посвященная
татарским писателям- жертвам политических репрессий)

**Ход мероприятия**

**<u>Укытучы:</u>** Илебез тарихында “Сталин репрессиясе еллары” дип аталган сәхифә бар. Дәүләт эшлеклесенең фикерләре белән килешмәгән кешеләрне аның тәгәрмәчләре рәхимсез рәвештә изгән, юкка чыгарган. ОГПУ тикшерү органнары барлык катламнарга да үтеп кергәннәр, ялган гаепләр уйлап тапканнар, хөкүмәт өчен “уңайлы” булмаганнарга шул рәвешчә “халык дошманы” ярлыгы тагылган һәм алар юк ителгән.

Татар халкы бу сәясәтне 1928елда ук татый. РСФСРның милләтләр эшләре буенча Халык Комиссариаты әгъзасы М.Солтангалиев милли сәясәттә Сталин белән килешмәве өчен гаепләнә. “М.Солтангалиевның контрреволюцион оешмасы» дигән эш буенча 77 кеше хөкем ителә. Шуларның 21-е атарга карар чыгарылып, соңрак ул үзгәртелсә дә, 30нчы елларда аларны яңадан хөкем итеп аталар.Солтангалиев үзе 1940 елда юк ителә.

Хөкүмәт барлык уңышсызлыкларның сәбәпләре итеп илдә барган “корткычлык”ны күрсәтә. Юк итү механизмы бик җайлы эшләгән. НКВД

органнарында “өчлек”ләр оештырылган. Хөкем карары “үлем” яки “каторга” булган. Республика буенча саннар менә ни сөйли:

1934 ел: 264 кеше каторгага хөкем ителә.

1935 ел: 2меңнән артык кеше хөкем ителә, 11-е атыла.

1936 ел: 2,7 мең кеше хөкем ителә,2-се атыла.

1937 ел: “халык дошманнары”ның хатыннары һәм балаларын кулга ала башлыйлар.

1938 ел: юк итү планы- лимит кертелә., 513 үлем карары чыгарыла.

1939 ел: 1262 кеше каторгага хөкем ителә. Җәзалау органнары вәкилләре үзләре хөкем ителә башлый.

“Халык дошманнары”н милләтчелектә, фашистик оешмаларда тору, шпионлыкта, корткычлыкта гаеплиләр.

Репрессияләргә дучар ителеп, төрмәләрдә җәфа чигүчеләр авырлыкны үзләре генә күтәрми. “Халык дошманы” дигән ярлык аларның гаиләләренә кара күләгә булып ята. Хатыннарны эштән куалар, балаларын бармак белән күрсәтеп мыскыл итәләр, комсомолдан чыгаралар..., сугыш елларында әтиләре фронтта үлүчеләр салымнарны кимрәк түләсәләр, боларга бернинди ташлама да булмый.

Республикабызның “Хәтер китабы” 55 меңгә якын сәяси репресия корбанын теркәгән. Аларны аклау күп еллардан соң гына була.

1998нче елның 30нчы октябрендә элеккеге НКВД бинасы каршында, халыкта “Черек күл” дип йөртелә торган урында һәйкәл куелды. Архитекторы- Ирина Аксенова. Һәйкәлгә 4 телдә (рус, татар, инглиз, гарәп) “Кичер” дип язылган. Стеллаларда “А”дан”Г” хәрефенә кадәр 500 фамилия теркәлгән.

Казанда атылганнар Архангел зиратына җирләнгән була.Анда да мемориал таш бар.

Бүген хөкүмәтебеә әлеге канлы еллар корбаны булганнарның гаиләләренә материаль ярдәм күрсәтә. Тик иң әһәмиятлесе- халык хәтере. Бу чор вакыйгаларын истә тоту- киләчәктә мондый ялгышларның кабатланмавы өчен кирәк.

Сүз укучыларга бирелә. Аларның чыгышы гаепсезгә рәнҗетелгәннәрне искә алу булып яңгырасын.

**Монтаж:**

*Залда караңгылык. Күк күкрәү, яңгыр тавышы яңгырый.*

Илһамия: *(Х.Туфан. Битараф ай)*

Ай сыенды болыт артларына
Утлар сүнде. Тормыш йокыда...
Шәһәргә җил килә кыр ягыннан,
Юлда тузан туздырмый гына.
Урмандагы чәчәклардәндерме,
Җил мәйданга бал исе ташый.
Соңга калган юлчыдырмы, кемдер
Европаның диварын шакый... (шаку тавышы ишетелә)

Шаһит: Ишетелер дип шакыйдыр ул, бәлки,
Берәр утлы- уяу кешегә...
Шакый... һәм ул
Күптән түгелдәге
Таныш хәлне искә төшерә...
Илһамия: - Кем ул шакый... калын диварларны?
Кем ул анда? Сиңа ни кирәк?
Шаһит: -Бу, ди ул,- мин- Тарих,
Гаделлекне йөрим мин эзләп...
Илһамия: Нигә шулай, Тарих,
Яшерен генә,
Төнлә генә капка кагасың?
Хакыңны син инде мәйданнарда
Көпә-көндез яклый аласың!
Шаһит: Ә ай белми: мәктәп һәм төрмәләр
Гүя тигез яхшылар инде.
Әйтерсең лә яшерен каберләрдән
Асыл ирләр кайттылар инде... (шомлы көй яңгырый)
Илһамия: Усал тарих... Канлы кансыз тарих... Сугыш, үлем. Кешеләргә яшәү көче, тормыш яме алып килүчеләрнең илһамын да ул кисте.
Шаһит: Тарих мең дә тугыз йөз 34,5,6,7,8,9... Сталин репрессияләре корбаннары арасында татар халкының рухи кыйммәте: язучы һәм шагыйрьләре.
Илһамия: Өметсезлек, протест, гаҗәпләнү...
1укучы: (Х.Туфан “Ә йолдызлар дәшми”)
Унике ел яздым,-
Унике ел
Җүнсезлеккә каршы көрәштем.
Ә ул, бүген...-
Заман бүген аңа
Тулы ирек биргән. күрәсең.
Кайларда сез
Шундый яман төндә,
Кайларда сез, изге дусларым?..
Яңа яра сала ил йөзенә
Гаделлекнең җүнсез дошманы.
2укучы: Раслап бары: “Денем өчен түгел,
Көнем өчен яшим!- дигәнне,
Дегетли дә кадерле ирләрне
Сата илнең һәрбер кибәге...-
3укучы:Ил йөрәге матәм кичергәндә,
Бәйрәм итә җүнсез типтереп,
Дозорлыкны- гадел изге эшне
Явызлыкка корбан иттереп.
4укучы:Кояшка син, йөрәк, йолдызларга:

-Бу ни хәл?- дип сорау бирәсең?
Алар дәшми...
Җүнсезлекнең дәвер, күпмегәдер,
Бәйле кулын чишкән күрәсең...
5укучы: (Ф.Кәрим)
Калды Казан, киттем Себергә.
Озаккамы? Бәлки гомергә.
Ишетеп кенә белгән ят җирләрдә,
Ристан булып, зарыгып йөрергә.
6укучы: (Х.Туфан. “Тышта давыл”)
Таллар кистем, баулар иштем,
Саллар салдым суларга.
Китәр ягым- уңда да бит-
Җилләр исә сулларга.
7укучы: (Р.Вәлиев. “Чират”)
Кем чираты?
Базар палачының
Күтәрелә канлы балтасы...
Стенадан көлеп карап тора
Халыкларның үги атасы.
8укучы:Кем чираты?
Дәште салкын аваз,
Авыр аваз, гүя кургашын.
Күрдем кебек базар чиратында
Горур башын Фәтхи Бурнашның.
9укучы:Кем чираты?
Мыек асларыннан
Саркып чыга зәңгәр усаллык.
Диварларны җимермәкче булып,
Башын бәрә Шамил Усманов.
10укучы:Кем чираты?
Дөньяларның бүген
Сугыш базарына тиң чоры
“Исән булса башлар, кайтырбыз!”- дип
Саубуллаша Кәрим Тинчурин.
11укучы:Кем чираты?
Бар кешеләр өнсез:
Юк шаярган, көлгән, уфтанган.
Аваз килә: “Мә, партия, мине!”-
Соңгы бүләк аңа Туфаннан. *(БВС чоры көе яңгырый)*
Шаһит: Фидакарь улларын җәзалаган илгә тарих сынавы... Бөек Ватан сугышы... Илне яклар. Саклар өчен ирләр кирәк... генераллар, инжененрлар, фидакарьләр... Ә алар атып үтерелгән, кешелеге кимсетелгән. ГУЛАГ аша 35-53нче елларда 18 миллион кеше узган...
1укучы: Илгә куркыныч янаганда без анда, фронтта булырга тиеш.

Шаһит: Югары органнарга бер-бер артлы хатлар ява. Кичәге политическийны бары штрафбат һәм алгы сызыкта булу көтә ала. Ләкин алар бәхетле, сугышка китеп, булмаган гаепләрен каннары белән юа алганнар.
2укучы:Төрмәдән азат ителеп фронтка киткән Ф.Кәрим хатынына менә нәрсә дип яза:"Бүген өченче декабрь, бу безнең гаиләбезгә үткән ел үлчәве белән булмас зур шатлык китергән көн... Шул көн шатлыгы тудырган бөтен көчемне фашизмга каршы көрәшкә юнәлдерәм."
3укучы:Мин рядовой солдат бу сугышта
Тик бер нәрсәм белән аерылам.
Рядовойлар төнен йоклаганда
Мин йокламыйм шатлык, кайгыдан (Ф.Кәрим)
Илһамия: Тоткынлыкта булганнары да күңелләре белән сугыш кырларында. Ватандашлары арасында...
4укучы:Мөмкин икән- якла мине, язмыш!
Түгел икән- ирек синеке...
Без- күнеккән: без тау күтәреп тә
"Эһ" димәгән кырыс илнеке.
5укучы:Илнең исемен саклар өчен әгәр
Безнең башлар, безнең гомерләр
Утлар эченә керә ала икән,
Димәк алар яман түгелләр
6укучы:Сораучылар булса, җиткезегез:
Менә шундый ирләр идек без...
Сау калганнар,
Безнең соңгы сүзне
Илебезгә, зинһар, илтегез. (Х.Туфан)
Илһамия: Ярый әле... Ярый әле бөтен дөнья кул селтәгәндә алар булган. Аларның мәхәббәте яшәргә көч биргән. Алар... әниләр, апалар, сөйгән ярлар. (*Х.Туфан "Әйткән идең" көе яңгырый)*
7укучы:Х.Туфанның Луизасы канын сату хисабына иренә передчалар ташыган...
8укучы:К.Тинчуринның Заһидәсе ире үлеменнән соң да аның эшен дәвам иткән...
9укучы:Ф.Кәримнең Кадриясе, сабырлыгын җуймыйча, башта төрмәдән, аннан фронттан көткән...
10укучы:Барысы да мәхәббәтләренең көченә ышанган кебек, якыннарының гаепсез булуына аз гына да шикләнмәгәннәр.
11укучы: (Х.Туфан. "Тамчылар ни диләр?")
Тәрәзәңә "җилләр" бәрелгәннәр,
"Сагынма!" дип янап киткәннәр...
Кунмагансең... Эштән сөрелгәнсең...
Еллар сине донор иткәннәр.
1укучы:Посылкалар белән ярдәм иттең;
-Без бит илдә... өйдә бит...- дидең.
Ә ул ярдәм

Каныңа алыштырган
Паекларың икән бит синең.
2укучы:Баш иям дә рәсемең каршында мин,
Күзләреңә багам тилмереп,
Яшьле күзен Мадоннага текәп,
Сүзсез калган Рафаэль кебек...
Тәрәзәмә кунган ак күгәрчен
Гөрли-гөрли канат кагына.
Кагына да уйнап очып китә
Син яшәгән өйләр ягына.
3укучы: (Ф.Кәрим “Кадрия”)
Ә мин калам тынчу таш төрмәдә,
Тимер рәшәткәгә баш иям.
Өзелергә җитеп сыкрый күңелем
Сагынудан сине, Кадриям.
4укучы:Кемгә тидек?
Кемне рәнҗеттек соң?
Кем соң безне шулай каргады.
Сак белән сок кебек моңаябыз,
Арабызда Урал таулары... (Х.Туфанның “Агыла да болыт агыла” шигыренә көй яңгырый)
Шаһит: тарих мең тугыз йөз 56. КПССның XX съезды... Реабилитация. “Халык дошманы” дигән ялган, пычрак исемне юып төшерү өчен тулы бер гомер кирәк була.
5укучы:Яхшы ата, яхшы аналарның
Яман түгел баласы идек.
Яманлыкның күзенә баса-баса
Тантанага барасы идек.
Илһамия: Үзләрен ничаклы югалтуларга дучар иткән туган илләренә кайту теләге аларны ташламый. Кайталар... Кемнең исеме генә, ә кемнәр үзләре дә...
6укучы:Фатих Сәйфи- Казанлы- атып үтерелә...
7укучы:Сәгыйть Сүнчәләй- атып үтерелә...
8укучы:Кәрим Тинчурин- атып үтерелә...
9укучы: Гомәр Толымбай- атып үтерелә...
10укучы:Шамил Усманов-сорау алганда кыйнап үтерелә...
11укучы:Фәтхи Борнаш- атып үтерелә...
1укучы: Фатих Кәрими- атып үтерелә...
2укучы:Галимҗан Ибраһимов-төрмә лазаретында үлә..
3укучы:Галим Мөхәмитшин- атып үтерелә...
4укучы: Сәләх Атнагулов- атып үтерелә...
Шаһит: Гали Рәхим, Ибраһим Сәлахов, Гурий Тавлин, Адлер Тимергалин, Мин Шабай, Хәсән Туфан, Сәрвәр Әдһәмова, Мирсәй Әмир, Садри Җәлал кайту бәхетенә ирешәләр. Әле ярый! Кешелек үткәннәрне мәңге гафу итә алмас иде. Тик монда да аларны кочак җәеп көтүчеләр юк шул.

5укучы: “ Ун ел! 26 белән 36 арасындагы алтын еллар! Яшьлегемнең иң гүзәл, иң шаулы, иң мөкатдәс көннәре! Алар шушы ике ишек арасында калды... Нигә? Нигә соң мин аксак? Нигә мин йолкыш? Ун ел элек мин әле йолкыш та, аксак та түгел идем ич? Нигә?” Бу И.Салахов сыкранулары...
6укучы: (Х.Туфан. “Җилләр исә”)
Урлады юлдашны язмыш,
Талады, каһәр!
Сердәшем китап та дәфтәр
Таңнарга кадәр...
7укучы:Тырнагын, тутык тырнагын
Иңемнән алды.
Ярасы ләкин озакка
Үзәктә калды.
8укучы:Кайда сез
Безне юлларда
Таный белгәннәр?
Яраларны бәйләгәннәр,
Сулар биргәннәр?
Кайда сез?
9укучы:Давылга әгәр юлыксам
Болытлы төндә,
Эндәшим фонарь сорап мин
Кемгә соң? Кемгә?
10укучы: (Г.Морат “Черек күл”)
Черек күлгә кармак салдым,
Еллар аша үрелеп.
Айкалды күл, чайкалды күл,
Сере китте түгелеп.
11укучы:Айкалды күл, чайкалды күл,-
Чайпалды күңеләрем.
Татарның күпме затлысы
Чүплеккә түгелгәнен
Уйладым да уем качты
Текәлдем калкавычка...
Котылсын заман сәяси
Капкыннан, алдавычтан.
1укучы:Кешенең кадере булсын,
Кабере булсын җирдә.
Саклансын заман-капмасын
Кабаттан сыйнфый җимгә.
2укучы:Күпме табут кайтты илгә.
Күпмесе- безгә кордаш...
Кай зиратта ята, димсең,
Якташың Фәтхи Бурнаш?
3укучы:Кай зиратта ята димсең,

Хөр уйлы гали җаннар?
Мирсәет Солтангалиев,
Тинчурин, Галимҗаннар?
Илһамия: Шигырьгә күчәдер, җанга
Сыймаган борчу, кайгың...
Ярый әле яд итәргә
Кабере бар Тукайның.
Кадере бар...
Шөкер әйтеп,
Коенабыз данында.
Кабере бар...
Яшәсә дә
Халыклар зинданында.
Шаһит: Ә бит кемнәрдер синең дә
Шәхесеңә тукына.
... Черек күлдә дога кылдым
Шәһитләр рухына.
Кешеләр! Акыл, намус, хакыйкать, бурыч, дуслык, мәхәббәт- алар булса гына без исән. Онытмагыз!
4укучы:Онытмабыз. Тарих усал, диләр. Ләкин аны кешеләр төзи. Сез, без.
5укучы:Онытмабыз. Тормыш нинди сынаулар бирсә дә, көчле рухлы, чын кешеләр баш ими.
6укучы:Онытмабыз. Алар язмышы- безгә үрнәк: палач булмас өчен, корбан булмас өчен...
7укучы:Безнең бабаларыбыз арасында да репресия корбаннары булгандыр. Онытмыйк аларны...
8укучы:Арабызда бабалары палачларның ярдәмчеләре булганары да бардыр. Кичерегез, зинһар...
9укучы:Без үткәннәрне үзгәртә алмабыз. Ләкин хакыйкатьне белү киләчәктә ялгышлар ясамау өчен кирәк.
10укучы: Без- яңа заманның яңа кешеләре. Тарих хаталарының бәяләре төзәтеп булмаслык икәнлекне күреп торабыз. Җирдә иң зур байлык кеше икәнлекне онытмыйча яшик!

## Методический замысел мероприятия и обоснование его темы:

Преподавание литературы всегда тесно связано с определением исторических событий. При изучении монографических тем творчества писателей обязательно заглядываешь в биографические данные. Слово «был репрессирован» вызывает у учащихся живой интерес. Наиболее увлеченным предлагаются мини- исследования о причинах обвинения и дальнейшей судьбе писателей. Судьбы жены Х.Туфана, актрисы Луизы, которая за счет донорской крови носила передачи, но не дождалась его; К.Тинчурина, застреленного еще в 38-м, но объявленного умершим в 47году; Ф.Карима, чудом не утонувшего на барже с другими заключенными, вызывает сочуствие, вырабатывает личностную позицию учащихся. Всегда возникает

вопрос о том, кого еще постигла такая судьба. Учащиеся в частном порядке знакомятся с историей репрессий. Но нам хотелось создать некую целостную картину тех лет по представлению самих писателей.

По этой причине было решено попробовать огласить имена известных литераторов, используя их произведения на данную тему. 30 октября 1998 года в Казани на «Черном озере» был открыт памятник жертвам политических репрессий. Называется он «Прости»- это просьба о прощении за покалеченные судьбы. Данное мероприятие тоже должно явиться мольбой о прощении, через память…

**Тип мероприятия:**

-обобщение и систематизация знаний, восприятие через призму литературных произведений событий былых лет.

**Форма мероприятия:**

- литературная композиция- монтаж из литературных произведений, информирование с фактическими данными, ознакомление с книжной выставкой произведений репрессированных татарских писателей.

**Цели и задачи мероприятия:**

-пробудить интерес к личности репрессированных татарских писателей;

-развивать умение восприятия художественных произведений;

-ознакомить с фактическими данными о хронологической последовательности событий репрессии;

-информировать учащихся с произведениями о репрессии, с литературным наследием жертв репрессий и произведениями современных писателей о событиях тех лет;

-показать отношение сегодняшних властей и общественности к Сталинским репрессиям;

- воспитание патриотизма, уважения к личностям;

**Методы и технологии работы учителя:**

- описание исторических событий, явлений и процессов;
- воспроизведение художественных произведений;
- ознакомление с книжной выставкой;

**Форма организации деятельности:**

-фронтальная

-групповая

**Оборудование мероприятия, источники информации**:

Литература:

1. Галләмова Ә.Г. һ.б. Татарстан һәм татар халкы тарихы. XX-XXI гасыр башы: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11нче сыйныфы өчен уку ярдәмлеге.- Казан: “Хәтер”,2009

2. Р.Мостафин. Репрессияләнгән татар әдипләре.- Казан: Татар. кит. нәшр.,2009

3. Кәрим Тинчурин: Истәлекләр, шигырьләр.- Казан: Татар. кит. нәшр.,2003

4. Туфан: Истәлекләр, шигырьләр.- Казан: Татар. кит. нәшр.,2000

5. Х.Туфан: Лирик шигырьләр.- Казан: Татар. кит. нәшр.,1985

В монтаже использованы следующие стихотворные произведения:

- Х.Туфан “Битараф ай”
- Х.Туфан “Ә йолдызлар дәшми”
- Х.Туфан “Тышта давыл”
- Х.Туфан “Тамчылар ни диләр?”
- Х.Туфан “Җилләр исә”
- Ф.Кәрим “Кадрия”
- Р.Вәлиев “Чират”
- Г.Морат “Черек күл”

Музыкальные фрагменты:

- Фрагмент песни “Священная война”
- Фрагмент песни на слова Х.Туфана “Агыла да болыт агыла” (музыка А.Бакирова)
- Фрагмент песни на слова Х.Туфана “Әйткән идең”(музыка М.Макарова)

**Предварительная подготовка:**

После выпуска в свет книги Р.Мостафина “Репрессияләнгән татар әдипләре.”( Казан: Татар. кит. нәшр.,2009) на уроках изучения творчества писателей, которые вошли в данный сборник всегда отводится время на изучение их жизни в те годы. Учащиеся- участники и зрители данного мероприятия, знакомы с некоторыми биографическими данными. В монтаж включены те стихи, которые знакомы учащимся по урокам литературы, а так же совершенно новые для слуха зрителя.